ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
Чернышевка авыл җирлегенең Каймар ав. торак пунтында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

15 ноябрь, 2022 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, "2023 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм торак пункт территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлегенең Каймар ав. торак пункты территориясендә яшәүче һәр балигъ яшьтәге кешедән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне:

- Каймар ав. поселок эчендәге юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу;
- Каймар ав. урамнарны яктырту өчен яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру;
- Каймар ав. чишмәсен төзекләндерү;

үтәү буенча юллау белән килешәсезме?"

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

дигән сорау буенча 2022 елның 15 ноябрендә 14 сәг. 00 мин. узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 364 (өч йөз алтмыш дүрт) кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 264 кеше, бу 72,5 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" позициясе өчен гражданнар җыенында 259 (ике йөз илле тугыз) катнашучы тавыш бирде;

"КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 5 (биш) катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чернышевка авыл җирлеге Каймар ав. торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.

2. 2023 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге Каймар ав. торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 1000 (бер мең) сум суммада үзара салым акчаларын кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Каймар ав. поселок эчендәге юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу;
- Каймар ав. урамнарны яктырту өчен яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру;
- Каймар ав. чишмәсен төзекләндерү.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче О. А. Маланин